| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.01.2025 Олы Кайбыч ав. № 10

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 августындагы 316 номерлы карары белән расланган Су объектларында муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган су объектларында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнары билгеләү методикасына 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 августындагы 316 номерлы карары белән расланган Су объектларында муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| т/б № | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение житәкчесе | 27 500 |
| 2 | Оператив дежурный | 21 200 |

».

2. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында http://kaybici.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров